СОВЕТ
СТАРОИЛЬДЕРЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИЛЬДЕРЕК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

03 август 2026 ел Иске Илдерәк №25

**Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 20.10.2015 N 8 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ Федераль законы, Аксубай муниципаль районы « Иске Илдерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1. Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 20.10.2015 N 8 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (Советның08.06.2018 ел № 73, от 12.11.2018ел № 83, 29.11.2018ел №88, 14.12.2019ел № 118, 24.10.2023ел № 62, 13.11.2024ел № 85, 19.01.2026 ел №15 карарлары редакциясенә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

1.1. һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан гаражлар һәм машина урыннары; хуҗалык корылмаларына карата 0,1 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга;

1.2. 2 статьяның 2 пунктында фатирлар, бүлмәләргә карата 0,2 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга:;

2. Әлеге карар 2027 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Иске Илдерәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм законда билгеләнгән вакытта Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://aksubayevo.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы А.А. Морозов